

Әлеге конне кvбрәк Мордовиянен конбатыш районнарында, Ләмбе-рәнен Пензяткасында һәм башка берничә авылда яшәгән татарлар билгеләп vтә.
Һәр бәйрәмнен vз тосе, vз йолалары, vз тәртибе булган тосле әлеге коннен дә vз тәртибе бар.      Үткән атнада христианнар зурлап Пасханы бәйрәм иттеләр. Ә татарларда бу кон «Кызыл йомырка», «Йомырка бәйрәме», «Чип-чип» диләр. Татар һәм рус йолалары, охшаш формада булсалар да ботенләй башка мәгънә йортәләр. Руслар Пасха конендә Иисус Христоснын воскрешениесе-терелvен билгелиләр һәм буялган йомырка дин тотучылар очен шатлыклы вакыйганын символы булып тора. Ә татарларда «Кызыл йомырка» дини булмаган мәгънәгә ия – бер-беренә доньяны жанландырган яз башы белән килгән иминлек, саулык теләv коне.
Әби-бабайлардан калган йола бу. Бу коннен иртәсеннән vк кунакка «аягы жинел» дип саналган бала чакырыла булган (хәзер авылларда кечкенә бала булса - килә). Ойгә кергәндә ул иминлек һәм сәламәтлек тели. Шуннан сон ана кvчтәнәчләр - йомырка, конфет һәм акча бирәләр. Әлеге ике бәйрәм дә - дуслык бәйрәме. Кадошкино районы Латышовка, Большие Поляны авыллары халкы, тирә-як кvрше авыллар халкы белән дус яшәгәнгә, элек тә Пасха бәйрәме кәефе безгә дә тәэсир итми калмый иде, бvген дә бу кәеф безгә кvчте, диләр. Мәсәлән, Мордовиянен кайбер районнарында шикелле әлеге авылларда “Чип-чип” дигән балаларнын йомырка жыеп йоргән коне Пасха vткәргән конгә туры килә. Балалар буяулы йомырка, тәмлушкалар жыя; хужабикәләрнен кайберләренә шулай жырлап яки яттан сойләп тә калдыралар: «Чип-чип чебәрvк, Йомыркасы югарук. Ак тавык, кvк тавык, Ходай бирсен кvп тавык...», ә кайберләренә шундый дәвам белән сойләгәннәр: «Артыгызда кvлегез, Мина йомырка бирмәсәгез, Тавыкларыгыз батып vлегез».
Быел, «Юлдаш»нын элекке коррес-понденты, тумышы белән Темников районыннан Гульфироза Илькаева «Кызыл йомырка» бәйрәме турында интернет битендә шулай язган; укып карагыз: «... Кичә лентаны карап чыктым һәм Пасхада Мордовиянен бер традициясе турында сойләгән блогер постына тап булдым. Кем белми, мин - Мордовиядән татар кызы. Башта кечкенә генә Енгураз авылында vстем, аннары зуррак Тархан авылына кvчтек. Беренчесе - татар авылы, икенчесендә - татарлар, мукшылар, руслар яши. Димәк, кичә пост укыйм һәм башымда бала чагымдагы рәсем чиерткәндәй калкып чыга: әни иртә-иртә уята да, тәрәзәдән чыгып, ишектән керергә кирәк, ди. Ә аннары вооооон кайдагы авыл халкына барырга, дип куша. Православлыларда Пасха конен татарлар бәйрәм итмиләр, ләкин буялган «Кызыл йомырка» коне бар. Һәм бу кон очен vз традицияләре бар. Мәсәлән, «жинел» аягы булган бала, ел унышлы vтсен очен, тәрәзә аша чыгарга һәм ишек аша керергә тиеш булган. Монын очен ана монетка биргәннәр. Әгәр дә сез шул жинел аяк хужасы булсагыз, алдагы конне иртән кvршеләргә керергә чакыру алырга момкин иде һәм алмашка тәнкә, бер пакет тәм-томнар, суган кабыгына буялган йомырка алырга була иде. Әнинен туган авылында да әлеге бәйрәм «Кызыл йомырка» дип атала, ләкин монда балалар иртәдән vк, зур пакет һәм татарча шигырь әзерләп, бер ойдән икенчесенә кvчеп: «Тавыкларыгыз салсын, кучатларыгыз бассын»ны янгыратып сойләгәннәр һәм буялган йомырка, кәнфит

һәм кайчакта тәнкә жыйганнар. Бер тапкыр әти-әни безне дә бәйрәмгә алып барды. Без иртән иртvк ойдән чыктык, кайтканда пакетларыбыз сорелгән буразна охшаган эз калдырды. «Оливье тазы» дигән гыйбарә бар, бездә - «пешкән йомырка тазы». Тарханлыларда халык кичтән шоколад, чупа-чупс, конфет, печенье, прәннек һәм, әлбәттә, йомырка белән пакетлар әзерли. Балалар әниләр, әбиләр, компанияләр белән йори. Татарлар, мукшылар, руслар - барысы бергә. Бу шундый шәп! Минем гажәпләнvемне кvз алдына китерегез, Наро-Фоминскига кvченгәннән сон мин мондый традицияләрнен ботен жирдә дә булмавын белдем... Кичә блогернын шәрехләренә кереп, Ульяновскнын кайбер районнарында ойләр/фатирлар буенча, Пенза олкәсендә йорvләрен укыдым. Янәсе, шатланмагыз, Мордовия, сез уникаль тvгел.
Мондый традиция турында ишеттегезме? Минем очен ул халыклар дуслыгы, бердәмлек, vзара анлашу һәм хормәт турында.»
Россия этнографлары, татар бел-гечләре билгеләп vткәнчә, мондый бәйрәм кайбер вариацияләр белән Идел буе һәм Урал татарлары тарафыннан билгеләп vтелгән. Анын барлыкка килvе башка халыклар белән якын кvршелек тәэсирендә милли традицияләр һәм гореф-гадәтләрнен эволюциясе белән бәйле, дип язганнар. Мәдәниятләрнен тормы-шыбызнын торле якларында vзара vтеп керvе илебезнен барлык халык-ларын бердәм социаль бергәлеккә берләштерә. Бvгенге конгә кадәр сакланган «Кызыл йомырка» коне, бәйрәме дуслыкны символлаштыра. Ул - доньяда ин кирәкле монәсәбәтләрнен берсе. Дуслык булса гына жир шарында тынычлык хокем сорер. Дуслык белән кочле без. «Кызыл йомырка» коне дә шуна дәлил.

**Наилә НАСЫРОВА**